Рузил Фазлыев

# БАКЧАДАГЫ ЧИЯЛӘР

Шигырь. Том 10. Стихи

Рузил  Фазлыев

# Бакчадагы чияләр. Шигырь. Том 10. Стихи

«Издательские решения»

**Фазлыев Р.**

Бакчадагы чияләр. Шигырь. Том 10. Стихи / Р. Фазлыев — «Издательские решения»,

ISBN 978-5-00-600440-5

Чираттагы җыелган шигырьләр тупланды бу китапта. Төрле темаларга кагылышлылары бар. Аерым темаларга бүлеп тупланмаган. Укучы үзе теләгәнен карап укый ала.

ISBN 978-5-00-600440-5

© Фазлыев Р.
© Издательские решения

# Содержание


Бакчадагы чияләр 6
Халәт алышыну 7
Катлаулы ураулы 8
Нигә күтәргә 9
Ник алай 10
Хәлләр ничек 11
Чама сүзе 12
Артык олы булса 13
Чәчәк язмышы 14
Кичләр 15
Безнең китап 16
Рәхмәт яусын 17
Язасы килә 18
Матурлык 19
Югалтулар 20
Гомер агышы 21
Тау 22
Юлда булу 23
Син кайгырма 24
Үпкәләмә авылым 25
Аналар 26
Уйлар белән 27
Кешенең күзгесе 28
Яңа тарих 29
Шундый чак 30
Конец ознакомительного фрагмента. 31

# Бакчадагы чияләр
# Шигырь. Том 10. Стихи

# Рузил Фазлыев

© Рузил Фазлыев, 2023

ISBN 978-5-0060-0440-5 (т. 10)
ISBN 978-5-0056-9347-1
Создано в интеллектуальной издательской системе Ridero

# Бакчадагы чияләр

Өй артында үскән чияләрне,
Чия бакчасыда диярлек.
Чияләре пешеп сусыллангач,
Агачлары башын иярлек.

Чия агачлар бик аз кешедә иде,
Бездән күпләр алды чияләр.
Ул чияләр инде картаялар,
Яңалары үсеп киләләр.

Ап ап чәчәк чагы бакчаларның,
Фотоларда гына сакланды.
Бик күпләрнең бакча чияләре,
Шушы чияләрдән башланды.

Заманалар шуный булган инде,
Тирә якта җимеш- әрәмә.
Бәрәңгене күбрәк утырткannар,
Калдырмыйча җирне әрәмгә.

Өй артында, үсте чияләре..,
Чия тәме шуңа якында.
Шуңа тагы искә алдым әле,
Бакчадагы чия хакында.

# Халәт алышыну

Көтмәгәндә халәт алышыну,
Аллаһының олы нигъмәте.
Аңлашыла… мондый үзгәрешкә,
Кеше көче генә җитмәсе.

Аллаһ исеме белән бәйләмичә,
Ниләр кеше кыла ала соң…
Язмыш юлын – алдан язылганын,
Кемнең көче бора ала соң…

Авыр икән моны аңлаулары,
Тәккәберлек кайчак җиңә ала.
Ишеткәнне бераз белгәннәрне,
Нигә икән баштан, җил ала…

Кабатланмый торган яшәүләрне,
Үз – үзебез нигә бозабыз…
Алданабыз ялган байлыкларга,
Буш кул белән аннан «узабыз».

# Катлаулы ураулы

Берәүнең юллары катлаулы,
Берәүнең юллары ураулы.
Кемнәрдер, каядыр киттеләр,
Кайдадыр юллары югалды.

Әллә ул мәшәкәт, әллә ул рәхәт,
Бер минут вакытың булмавы.
Эш белән булсада тормышта,
Кешенең тышауда тормавы.

Берәүгә агачы, берәүгә җимеше…
Кемгәдер өлеше, тия тик тиресе,
Тормышта гел көтеп ятканда,
Көткәннең килә шул киресе.

Биргәнен күрмичә ярамый,
Онытмый, ул каян килүен.
Күңелдә җиңеллек булганда,
Аллаһның рәхмәте диюең.

Кешедә, кешелек сыйфаты,
Тормышта күберәк саклансын.
Кабатлап Аллпһның исемен,
Һәркөнне иртәләр башлансын.

# Нигә көтәргә

Таңнар ата һәркөн яңа булып,
Ә үткәнне нигә көтәргә…
Мөмкин түгеллеген белә торып,
Нигә аны өмет итәргә.

Ә, үткәннәр алар үтелгәннәр,
Якты эзләр бәлки калгандыр…
Берәү өчен гади кебек булып,
Икенчене утка салгандыр…

Берәү өчен олы хыяллары…
Икенченең үтеп баруы.
Тормыш шулай дәвам ителсәдә,
Күңелләрдә яра калуы…

Биргән вакыт үтеп киткән инде,
Кирәк вакыт бергә яныргa.
Кирәк түгел көтү үткәннәрне,
Алга таба кирәк барырга.

Кыйммәтедә шунда үткәннәрнең,
Күңелләрдә, истә калуы…
Нинди генә эзләр калдырсада,
Онытылмый һаман, баруы…

# Ник алай

Берберсен күңелләр табалар,
Бик ерак булсада аралар…
Кайвакыт үзләре белмичә,
Күпмедер янәшә баралар…

Эзләпме табалар парларны,
Кемнәрдер, нигәдер табалмый…
Сайлапмы табыла тиңнәре,
Кайвакыт тиңнәрдә, баралмый…

Ник алай тормышта, була соң,
Җавапсыз калалар сораулар…
Теләгең бик олы булсада,
Файдасыз булалар юраулар…

Бәлки ул барыбер кешедән,
Лаеклы булганнар табышу…
Бәлки ул кемнеңдер ярдәме,
Мәңгелек пар белән танышу..

Сихри көч сизәдер күңелне…
Якынлык булуын …нурларын.
Әйбәтләр, әйбәткә очырый,
Ә сиңа лаеклы булганың.

Ходай биргән, язмыш дибез кайчак,
Үзебезнең бөтен кылганны…
Ике кеше генә саклый ала,
Гомерлеккә парлар булганны…

# Хәлләр ничек

«Хәлләр ничек» дибез күрешкәндә,
«Сәләмәт бул» дибез киткәндә.
Исәнләшми яшәп була мени,
Кешеләрне хөрмәт иткәндә.

Сәләмләшү – сәләмәтлек теләү,
Дога кылу кебек түгелме…
Чын күңелдән әгәр әйтә алсаң,
Кешеләргә сәләм сүзеңне.

Тирән мәгънә бит һәрбер сүздә,
Теләкләләрең ихлас булганда,
Тормышларда ялгыз булалмыйсың,
Сәләмләшеп һәрчак торганда.

Биргән сәләм, олы савап булыр
Кайтмый калмас сиңа, үзеңә.
Күңелеңә җиңеллекләр булып,
Һәрбер әйткән ихлас сүзеңә.

Сәләм булсын, шигырь юлларыда,
Укый алган һәрбер күңелгә.
Аллаһының олы нигъмәте бит,
Сәләм бирә алу бүгендә!

# Чама сүзе

«Чама» сүзен бөтенебез белә,
Кемнәр белә аның күләмен.
Сизми калдык, тормышларыбызга
Чамасызлык килеп кергәнен.

Чама сүзе, кыска булсада ул,
Озатып бара гомер буена.
«Чама минем болай дөрес» диеп,
Кереп калган кеше уена.

Чама сүзе, бөтен эшләр өчен,
Чама сүзе, барлык аш өчен.
Хәттә зыяратта бакыйларга,
Баш өстенә куйган таш өчен.

Чаманы бит һәркем кабул итә,
Төрлечәрәк кеше чамасы.
Арбалары күптә, җәйләр өчен,
Кышлар өчен булмый чанасы.

Күрмәгәннең килә күрәсе,
Туймаганның килә туясы.
Кайларга соң, истә торсын өчен,
«ЧАМА» сүзен язып куясы?

# Артык олы булса

Көчле булыйк дибез яшәгәндә…
Авырлыклар аша үтәргә…
Каршы җилләр нинди булсаларда,
Барыр җиргә барып җитәргә…

Хыялларың артык олы булса,
Җитәр микән булган көчләрең.
Ярты юлда калып югалырмы…
Эшләмәкче булган эшләрең…

Кемнән, беләм ярдәм сораргада,
Күңел тартмый барсын сорарга.
Сорап кына яшәү ялгыш кебек,
Үзеңә күп гамәл кыларга…

Сорамыйча булмый Ходайданда…
Булган көчне бераз сакла дип.
Явыз көчтән, хәлсезләнгән чакта,
Көч җитмәсә безне якла дип…

Калган көчләр калган юллар өчен,
Юл бетмәсә, көчләр табылыр.
Яшим дигән, тыныч күңел белән,
Бер Аллаһка бары табыныр…

«Кеше туа җиргә ризыгы белән»…
Хәдистә бит шулай әйтелгән.
Көчсезләндем диеп әйтү түгел,
Төрле юллар диеп әйтүдән…

# Чәчәк язмышы

Чәчәкнеңдә була төрлеләре,
Кызыллары, зәңгәр, аклары…
Гомерләрнең кеше яшәгәндә,
Чәчәкләргә тиңләр чаклары.

Чәчәкне без нигә матур дибез,
Матур чагын гына күргәнгә.
Күрмәгәнгә шиңгән чакларында,
Чәчәк атуын гына белгәнгә.

Бәйрәмнәрне чәчәк бизәүче,
Чәчәкләргә, хәттә күмәләр…
Файдаланып матур мизгелләрдән,
Чүп иттереп чыгарып түгәләр…

Чәчәк менә шуның өчен үсә,
Кеше хисе шулай кыйммәтме…
Кеше күңеле булсын өчен диеп,
Бүләк биреләме кыйммәтле…

Кабатланмый мени кешедә дә,
Яшәештә, чәчәк язмышы.
Шиңгән чәчәкләргә әйләндерә,
Ялгыш кылган берәр ялгышы…

Бөтен ялгышларда язылганнар,
Кирәк түгел бары кабатлау.
Чәчәк язмышларын кабатласаң,
Үз үзеңне була яратмау.

# Кичләр

Көн азагы, кояш баеганда,
Килә шулай көннең кичләре.
Барлар чыгу өчен вакыт килә,
Нинди эшләр бүген эшләнде…

Кичләр алар көзне хәтерләтә,
Көз торгандай бик күп кичләрдән,
Тула күңел андый вакытларда,
Моңсуырак булган хисләрдән.

Кичләрне бит кемдер көтеп ала,
Башка тоомыш кичен башлана…
Ял буламы, әллә бал буламы,
Калган вакыт шунда ташлана…

Кичләрнең бар үзе законнары,
Караңгылык каплый дөньяны.
Төннәр буе кайчак яллар итә,
Көннәр буе эшләп туйганы.

Кичләр саклый бик күп серләрнедә,
Яшерелеп кала начарлык…
Икенче тын ачылгандай булла,
Кичләр җиткәч күңел ачарлык.

Чагыштыру өчен тагын мисал:
Гомернеңдә бардыр кичләре.
Күңел өшеттереп кайвакытта,
Салкын җилләр исеп киткәне.

# Безнең китап

Китап бите кебек, үткән көннәр,
Булмый, артка ләкин актарып.
Эчтәлеге кабатлана алмый,
Күңелләрдә кала сакланып…

Ташка баскан кебек битләре,
Төзәтүләр булмый керетеп,
Ул китапны бары саклап була,
Хәтер дигән җирдә йөретеп.

Китап яза җирдә һәрбер кеше,
Һәр кешедә үзенә язучы…
Язмыш дигән олы китабын,
Бизи, бизи яза алучы…

Китап яза кеше – олы китап,
Өсти өсти. көндә битләрен.
Үзе кеше белә ала микән,
Китабының язылып беткәнен.

Китап яза кеше, гомер буе,
Гомерлеккә килгән шикелле…
Җир йөзенә кеше килгәндә дә,
Шул гомергә килә бит инде.

Гомер бит ул җирдә яшәү чоры,
Димәк җирдә яшәү гомерлек.
Безнең китап була алсын иде,
Мәңгелеккә алып керерлек.

# Рәхмәт яусын

Рәхмәтне сорап алып булмый,
Үпкәләптә булмый аның өчен.
Рәхмәт хисе эчтә булу кирәк,
Рәхмәтлерәк булып калу өчен.

Сатылмыйда рәхмәт базарларда,
Керә алмый кеше төшенә.
Ул күңелнең бары бер кисәген,
Бирә алу башка кешегә.

Рәхмәт әйтү, әдәп билгеседә,
Күреп ярдәм яки изгелек…
Җавап сүзе әйтә белү кебек,
Канәгать булуыңны сиздереп.

Рәхмәтлелек кеше күңелендә,
Әйтә белсәң – синдә бар димәк.
Коры сүзгә кайтып калмыйча,
Ихлас булулары бик кирәк.

Рәхмәтлелек – күңел матурлыгы,
Саклый күңелләрнең киңнәре…
Җылы сүзләр җирдә бик күп түгел,
Рәхмәт сүзләренә тиңнәре.

# Язасы килә

Язасыда килә язасы…
Нидер килә язып каласы.
«Ниләр җитми сиңа» -диеп,
«Белмәссең» дип «Әдәм баласы».

Күбрәк син әллә яшәдеңме,
Күбрәк син әллә белдеңме…
Дөньяларның олы сынауларын,
Син бер үзең әллә күрдеңме…

Язам әле, үзем аңлаганны,
Ниләр белән күңел тулганны.
Белмәгәндәй, инде башкаларның
Күңелләре тулы булганны.

Була алмый икән буш күңелләр,
Күңел җыя тормыш өресен.
Ниләр белән күңел тулганлыгы,
Аз булсада… бераз күренсен.

Таныш хисләр очырамый калмый,
Таныш аваз, бәлки табылыр…
Якты мизгелләрен уятырда,
Ул яшьлеген кабат сагыныр

# Матурлык

Матурлык бөтен тирә як…
Кирәк бары күрергә.
Табыр өчен матурлыкны,
Өйрән күрә белергә.

Матурлык ул чәчәкләрдә,
Кешеләрдә матурлык…
Матурлыкның күплегенә,
Җирдә шаклар катырлык.

Матур итеп үстерәләр…
Матур итеп төзиләр…
Киенәләр зәвык белән,
Матур итеп йөриләр.

Сөйләшәләр матур итеп
Матур итеп көләләр.
Тормышларны ул үзгәртә,
Шуны күпләр беләләр.

# Югалтулар

Югалтулар була яшәгәндә,
Төрле вакыт, төрде күләмдә.
Җиңелләре, була авырлары,
Барысына кирәк түзәргә.

Ягалтулар кебек исраф гомер,
Әйтелмәгән җылы сүзләрең….
Югалтулар түгел мени инде,
Ни эзләгәнеңне белмәвең.

Юлсыз җирдә йөреп адашулар,
Әзер юллар буйлап йөрмичә.
Хыялларга гына бирелеп яшәү,
Якын булганнарны күрмичә.

Югалту бит, гомерләрең үтсә,
Читтән карап яшәп иманга.
Күпме әле ялгыш уйлар яши,
Кеше акылына сыйганга.

Югалтулар алып ыргыталар,
Бүгенгене ерак үткәнгә…
Югалтулар азырак булыр иде,
Бүгенгегә шөкер иткәндә…

# Гомер агышы

Кая ашыгалар бу болытлар,
Әллә җилләр шулай искәнгә.
Булсын иде шундый җилләредә,
Балачакка кире илеткәндә.

Уңай җилләр алып кайтыр иде,
Озын юлда, ясап туктаулар.
Әвен ясап җәен болыннарда,
Кабатланыр иде йоклаулар.

Аргы тугай, Бирге тугайлары,
Олы болын, Кылыч, Әгәшләр.
Әби булып бүген йөргәннәрнең,
Булган чагы яп – яшь кәләшләр.

Кире баштан тормыш туа кебек,
Кабатланыр кебек барсыда.
Сәяхәттә булу, уйлар белән…
Булгач ярый әле ансыда…

Кешегә бит шундый сәләт биргән,
Үткәннәрне искә төшерү…
Тормышыңа бәя бирү өчен,
Күңелең аша кабат кичерү.

# Тау

**Кешеләрне таулар җәлеп итә,**
**Үрмәләргә таулар өстенә.**
**Авырлыклар… җиңеп күтәрелү,**
**Һәркем өчен түгел, һичкенә**

**Тау башына менеп җитә алсаң,**
**Якынаер кебек күкләрдә…**
**Күпләр өчен биек тау башлары,**
**Ялганалар кебек күкләргә.**

**Биек тауга менеп җитеп булла,**
**Күкләр генә кала еракта…**
**Тауга менеп, күккә җитеп булмый,**
**Урау юллар эзләп, сорапта…**

**Таулар безгә биек булсаларда,**
**Анда юллар барыбер туктала.**
**Күккә юллар кеше өчен түгел,**
**Хыялларың нинди булсада.**

**Без тауларга шуңа үрмәлибез,**
**Югарыдан нидер күрергә.**
**Кабат килү әгәр мөмкин булса,**
**Кошлар булып җиргә килергә.**

# Юлда булу

Тормышларда кирәк микән көтү,
Яңа таңны көткән шикелле.
Әллә кирәк микән юлда булу,
Таңнар күптән аткан бит инде…

Таңнар ата, ләкин ул бары тик,
Кичәгенең генә давамы…
Шул ук эшләр, шул ук мәшәкәтләр,
Шул ук яңгыр һаман явамы…

Аңламакчы булып зур тормышны,
Нечкәлеген эзләп тапмакчы.
Белгәненә, барсы була алмый,
Ялан аяк йөри башмакчы…

Күпме акыл кеше сарыф итә,
Болар барысы, тамчы диңгездә.
Күңел һаман туя алмый нигә,
Җитәрлек бит бирә Ул безгә…

Гомерне без юллар дибез икән,
Ул юллардан кирәк барырга.
Туктасакта бары азга гына,
Яллар итеп бераз алырга…

# Син кайгырма

Син кайгырма, кайгы килсә әгәр,
Кайгыдан соң килер шатлыгы…
Кайгыларны кайгы алыштырмый,
Көтә сине алда шат көне.

Кайгырудан кайгы жиңеләйми,
Кемгә, үпкәләүдә урынсыз…
Күз алдыңа иртәгәне китер,
Күңелләрең бераз җылынсын…

Берсе артыннан алар берсе килә,
Сыналабыз шулай үсәбез…
Адым саен кыенлыклар аша,
Берәр бачкыч өскә күчәбез…

Гомер буө яши – яши җирдә,
Тормыш безне һәрчак өйрәтә…
Тормыш мәктәпләре кешеләрне,
Яхшылыкка бары үзгәртә…

Белә алсак, җирдә тормыш итү,
Яшәү белән бергә имтихан…
Сынауларның иң олысы өчен,
Җир йөзенә безне Ул җыйган…

# Үпкәләмә авылым

Туып үсеп туган туфрагыңда,
Үз юлларын җирдә тапканнар.
Чәчәк орлыгыдай, сибелешеп,
Төрле җирдә, чәчәк атканнар…

Үпкәләмә авылым зимагурга,
Читтә йөреп бәхет табалса.
Язмышына, шөкер итә итә,
Туган жирен искә алалса…

Күпме язмыш, җирдә үтеп китә,
Туган туфакта шытып, башланып.
Күпме үтеп авыр сынауларын,
Күпме яшәп кала шатланып…

Дәвам итә синдә туганнардан,
Яңа язмыш, яңа буыннар.
Тормыш башын алар, безнең кебек,
Туган җирдән алган булырлар…

Кайда гына кеше яшәсәдә,
Сагындыра торган урын бар.
Адашмаска тормыш юлларында,
Якты биреп торган нурың бар…

Үпкәләмә авылым киткәннәргә,
Читтән торып, якын иткәнгә.
Туган якның бер баласы булып,
Кайлардадыр гомер иткәнгә…

# Аналар

Язмыш диеп кенә уйласакта
Аналардан күпме өстәлгән…
Күпме ризык безгә насыйп булган,
Алар әзерләгән өстәлдән.

Тәүге тапкыр якты дөнья белән,
Танышулар каян башланган.
Үсеп җиттең, үзең сизмичәдә,
Ул пешергән тәмле ашлардан.

Балаларга күчеп кала кебек,
Аналарның йөрәк җылысы.
Унар тапкыр әгәр дога кылса,
Бала өчен булган унысы.

Кайларда соң калды ул вакытлар,
Күпмеләре калды исләрдә…
Көннәр үткән көннәр җил давылсыз,
Искә төшә ничә кичләрдә.

Күпме теләк алар теләгәннәр
Өмет итеп матур киләчәк.
Шөкер ителергә онытыла,
Бүгененә, алда бирәчәк.

Озатып йөрми микән догалары,
Озатып йөрми микән хисләре.
Күпер түгел микән бу тормышта,
Йокысыз үткәннәре кичләре.

Аналарның без бит балалары,
Буыннарның без бит дәвамы.
Көннәр үтәр саваплырак булыр,
Истә тотсак газиз ананы…

Шуның өчендә бит гыйбәдәтләр,
Һәр көн укый торган догалар.
Аналарны истә тотучылар,
Мәрхәмәтле җаннар булалар.

# Уйлар белән

Бер үк уйлар, бер үк җылы сүзләр…
Кешеләрне кайчак юата.
Кайчак авыр, кичләр җитсәләрдә,
Таңнары бит, назлап уята.

Дәвамнары, яки кабатлана,
Күргәннәре яки күрәсе.
Белмәгәннәр, буа буырлык,
Күрмәгәнне килә күрәсе.

Һәркем яши үзе теләгәнчә,
Үзенчә ул аңлый, фикерли.
Бөтенесе каян килгәнлеген,
Кайчагында уйлап бетерми.

Үтәмичә булган чикләүләрне,
«Тиеш» диеп, таңнар атуын.
Соңгы тапкыр булу мөмкинлеген,
Бүген көткән кояш батуын.

Тоя алган җәйнең яңгырларын,
Кыш көненең салкын җилләрен.
Аңлап калыйк, матур яши алыйк,
Мәңгелеккә җиргә килмәдең.

# Кешенең көзгесе

Бик озак яшереп тотсада,
Ачылы кешенең чын йөзе.
Күрсәтә бервакыт, сизмәстән,
Тормышта яшәеш ул үзе.

Кая соң чын йөзе, кешенең,
Байлыкта, эшендә, киемдә.
Тырышып, узарга башканы,
Төзегән зурырак өендә…

Баланың, атаның, ананың,
Заманча яшәүче түрәнең.
Көзгедә шикелле күренер,
Тормышта ул ниләр белгәнен.

Кешенең көзгесе – күңеле,
Ул шунда чын йөзен яшерә.
Яшереп яшәүләр авырдыр,
Карамый ул аның яшенә.

Кемнәрдер ояла, тыйнаклык,
Уңайлы кемгәдер маскалар.
Күрербез без кайчан ихласлык,
Барыбызга маскалар ассалар.

Яшереп буламы, булганны,
Алдашу юлыннан бармаса.
Юмартка әйләнми кешеләр,
Аллаһның биргәне калмаса!

# Яңа тарих

Җайлашумы әллә алдашумы,
Бөтен кешеләргә дус булу.
Сатылумы, әллә саташумы,
Дошман арбасында еш булу…

Чал тарихлы диеп сөйләсәктә,
Туган җирне, халык, милләтне.
Сүздә сөйләп, эштә эшләмәгәч,
Юкка чыга аның кыйммәте…

Тарих бит ул олы сабак кебек,
Төзәтмәслек була яралар.
Булганында саклап калалмагач,
Тарих битен шулай ябалар.

Купшы сүзләр, ерак дөреслектән,
Агылада һаман агыла…
Безнекеләр кая булып бетте,
Күчтеләрме аклар ягына…

Тарих саклый, бары булганнарны,
Бозучылар аны булсада.
Калмаска иде хыянәтче булып,
Ничек кенә авыр булсада…

Сакланганнар, бары котылырлар
Җир йөзендә явыз бар заттан.
Үзебезне хөрмәт итеп яшик,
Ярдәм сорап бары Аллаһтан…

# Шундый чак

Матур чагы була гомерләрнең
Гөрләп бара бөтен эшләрең.
Кәефеңне бозмый, онытыла,
Бик куркыныч булган төшләрең.

Яхшы дуслар, әйбәт кешеләр,
Очрыйлар тормыш юлыңда.
Бөтен дөнья тулган шатлык белән,
Уйланмыйда кайгы турында.

Сөйләр кешең, синең серләр өчен…
Сизелмиләр вакыт чикләре.
Уйландыра алмый ул вакытта,
Җитмәгәне белән җиткәне.

Кайчан үтеп китә ул вакытлар,
Җылы җилләр кебек иркәләп.
Бәхет мизгеләре үтә микән,
Никтер куя соңнан киртәләп.

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.